ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«25 »март 2021 ел. № 65-р

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2020-2021 уку елы сезонының «КЭС-БАСКЕТ» Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатының дивизиональ этапларын үткәрү турында**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасында 2020-2021 уку елы сезонының «КЭС - БАСКЕТ» Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатының дивизиональ этапларын үткәрү турында» 2021 елның 02 мартындагы под – 260/21 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында баскетболны популярлаштыру, укучыларны спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү, укучыларның сәламәтлеген ныгыту, сәламәт яшәү рәвешенә ихтыяҗ тәрбияләү, уенчыларның һәм командаларның спорт осталыгын арттыру, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәктәп укучылары арасында иң яхшы җыелма командаларны ачыклау максатларында:

1. 2021 елның 26-27 мартында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2020 уку елы сезонының «КЭС-БАСКЕТ» Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатының дивизиональ этапларын (алга таба - Мәктәп баскетбол лигасы чемпионаты) үткәрергә һәм оештырырга.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2020-2021 уку елы сезонының «КЭС-БАСКЕТ» Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатының дивизиональ этапларын әзерләү планы (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2020-2021 уку елы сезонында «КЭС-БАСКЕТ» Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатының дивизиональ этапларын әзерләү чыгымнары сметасын (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм эшләре бүлеге башлыгына Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатын оештыру һәм үткәрү буенча гомуми җитәкчелек һәм контроль тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенә Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатына чаралар әзерләү эшен оештырырга.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Олимп» спорт-савыктыру комплексы МБУ директорына мәктәп баскетбол лигасы чемпионатын уздыру өчен бина бирергә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Талантлар салават күпере» өстәмә белем бирү МБУ директорына катнашучыларны теркәүне, Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатын ачу һәм ябу тантанасын узыдруны оештырырга.

7. «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибына мәктәп баскетбол лигасы чемпионатын уздыру чорында медицина персоналын озатуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

8. Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлегенә, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең Әгерҗе районы күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатын үткәргәндә иминлекне һәм озатып йөрүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

9. «Татмедиа» АҖ филиалы «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы редакциясенә, «Әгерҗе радиосына» Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатын үткәрүнең барышы һәм нәтиҗәләре турында массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

10. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге күрсәтмә буенча чараларны гамәлгә ашырганда финанслау мәсьәләсен хәл итәргә тәкъдим итәргә.

11. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенә әлеге күрсәтмәдә күрсәтелгән вазыйфаи затларны әлеге күрсәтмәсе белән таныштырырга.

12. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

13. Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм бүлеге башлыгы Л.С. Имановага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2021 елнын 25
мартындагы 65-р номерлы күрсәтмәсенә
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2020-2021 уку елы сезонының «КЭС-БАСКЕТ» Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатының дивизиональ этапларын әзерләү планы**

| № | Чаралар исемлеге | Җаваплы вазыйфаи затлар | Башкару контроле |
|---|---|---|---|
| 1. | «Олимп» СОК» МБУ бинасында техник таләпләргә туры килүне тәэмин итү | «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ<br>«Олимп» СОК» МБУ | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм бүлеге башлыгы |
| 2. | Командалар һәм кунакларны каршы алу, мандатлы комиссия, ярышлар көннәрендә озата бару<br>Яшәү, туклану | «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ | |
| 3. | Укучыларның һәм судьялар командасының туклануын оештыру | «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ | |
| 4. | Чемпионатны ачу | Әгерҗе муниципаль районынын «Талантлар салават күпере» балалар иҗаты йорты» өстәмә белем бирү МБУ | |
| 5. | Массакүләм мәгълүмат чараларында чараларны яктырту | «Әгерҗе хәбәрләре» (килештерү буенча), «Әгерҗе радиосы» (килештерү буенча) | |
| 6. | Чаралар узган вакытта хокук тәртибен тәэмин итү | Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлеге (килештерү буенча) | Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлеге башлыгы (килештерү буенча) |
| 7. | Ярышларда катнашучыларны медицина белән тәэмин | "Әгерҗе үзәк район хастаханәсе" ДАССУ | "Әгерҗе үзәк район хастаханәсе" ДАССУ баш табибы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | итү | | |
| 8. | Ярышлар уздырганда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгынын Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең Әгерҗе районы күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге (килештерү буенча) | Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Әгерҗе районы күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге башлыгы (килештерү буенча) |
| 9. | Әгерҗе муниципаль районы территориясендә командаларда катнашучыларны озатып йөрү | «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ, Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча ЮХИДИ бүлеге (килештерү буенча) | «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы, Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча ЮХИДИ бүлеге (килештерү буенча) |

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетынын 2021 елнын 25
мартындагы 65-р номерлы
күрсәтмәсенә 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында 2020-2021 уку елы сезонында «КЭС-БАСКЕТ» Мәктәп баскетбол лигасы чемпионатының дивизиональ этапларын әзерләү чыгымнары сметасы**

| № | Чыгымнар исемлеге | исәбе | Бәя | Сумма |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Бер тапкыр кулланыла отрган стаканнар | 500 | 2,5 | 1250 |
| 2 | Бәдрәф кәгазе | 4 | 15 | 60 |
| 3 | Кәгазь сөлгеләр | 4 | 100 | 400 |
| 4 | Сыек сабын (0,5) | 2 | 80 | 160 |
| 5 | Антисептик (1л) | 2 | 650 | 1300 |
| 6 | Батарейкалар | 10 | 50 | 500 |
| 7 | Маскалар | 1 | 50 | 500 |
| | **БАРЛЫГЫ** | | | **4170** |